| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан<br>Старо-Имянское сельское<br>поселение Сармановского<br>муниципального района** | **ТатарстанРеспубликасы<br>Сарман муниципаль<br>районынын Иске Имән<br>авыл жирлеге** |
| **КАРАР<br>01.11.2024 ел** | **КАРАР<br>№ 110** |

Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 13 маендагы 149 номерлы Иске Имән авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Иске Имән авыл җирлеге советы карар итте:

1.Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында» Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Советының 2020 елның 13 маендагы 149 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 9 пунктының 6 абзацында «тапшыра сүзеннән соң» “түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненән дә соңга калмыйча сүзләрен өстәргә;

2) «5 статьяның 9 пуктына түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктча өстәргә:

–Россия Федерациясе Финанс министрлагы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентын билгели;”;

3) 9 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«туристлык салымы - 100 процент норматив буенча.»;

2. Әлеге карарның 1 пунктның 2 пунктчасы 01.01.2025 елдан үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда әлеге карарны игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Совет рәисе

Р.Ә.Исламова